Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә урта гомуми
белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Сабирҗанова Светлана Илдус кызының педагогик эшчәнлегенә
**бәяләмә**

Сабирҗанова Светлана Илдус кызы югары белемле, 1987 нче елда КГПИ тәмамлый, педагогик стажы 28 ел, югары квалификацион категориягә ия. Ул – эшлекле, эзләнүчән, яңалыкка омтылучы, гадел, таләпчән, иҗади эшләүче укытучы. Укыту-тәрбия эшендә белемле, көчле ихтыярлы, иҗади фикер йөртүче, матурлыкка омтылучы, милли үзаңлы шәхес тәрбияләүне максат итеп куя. Шушы максатка ирешү өчен үзенең дәресләрендә һәм сыйныфтан тыш чараларда төрле алым, методлар кулланып, традицион булмаган дәресләр уздыра. Светлана Илдус кызы үзенең эш методлары белән районның һәм мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучыларын да таныштырып тора. Районның татар теле һәм әдәбияты укытучылары каршында "Укучыларны рухи яктан формалаштыруда әдәбият дәресләренең роле", "Укучыларга тирән белем һәм күнекмәләр бирүдә, аларны тормышка әзерләүдә укытучының иҗади роле", "Татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты", "Татар әдәбияты дәресләрендә электрон дәреслекләр белән эшләү" дигән темаларга чыгышлар ясады. Быелгы уку елында татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен төбәкара семинарда 5 нче сыйныфта татар әдәбиятыннан "Барыбызга да таныш Шүрәле" (Г.Тукайның "Шүрәле" поэмасы буенча) темасына дәрес үткәрде. Дәрес район укытучылары тарафыннан югары бәяләнде. Ә 2012 нче уку елында 7 нче сыйныфта татар әдәбиятыннан "Г.Исхакыйның "Кәҗүл читек" әсәрендә милли йолаларның чагылышы" дигән темага республика укытучыларына дәрес биреп, үзенең эш тәҗрибәләре белән уртаклашты.

Светлана Илдус кызының укучылары татар теле һәм әдәбиятыннан олимпиадаларда актив катнашалар һәм призлы урыннар яулыйлар. 2013-2014 нче уку елында 10 нчы сыйныф укучылары арасында татар теленнән Абдуллина Камилә җиңүче, 7 нче сыйныф укучысы Хадиева Фирүзә татар әдәбиятыннан җиңүче, татар теленнән призер, 7 нче сыйныф укучысы Гыйниятуллина Чулпан татар теленнән призер булды. 2014-2015 нче уку елында Абдуллина Камилә татар әдәбиятыннан җиңүче булды. 2015-2016 нчы уку елында 9 нчы сыйныф укучысы Хадиева Фирүзә татар әдәбиятыннан җиңүче, 9 нчы сыйныф укучысы Галимҗанова Зилә татар теленнән призер, 5 нче сыйныф укучысы Әхмәтова Азалия татар теленнән призер булды.

Светлана Илдус кызы сәләтле укучылар белән эшләүгә зур игътибар бирә. Укучылары ел саен республика һәм район күләмендә үткәрелгән төрле конкурсларда, фәнни-гамәли конференцияләрдә актив катнашалар һәм югары нәтиҗәләргә ирешәләр. 2013 нче уку елында 10 нчы сыйныф укучысы Абдуллина Камилә "Татар лингвокультурологиясе: проблемалар һәм перспективалар" республикакүләм конференциядә чыгыш ясап Мактау грамотасына лаек булды. 2013 нче уку елында 6 нчы сыйныф укучысы Насыйбуллина Диана "Зирәк тиен" Бөтенроссия уен-бәйгедә татар

мәктәпләрендә укучы балалар арасында 3 нче урынны алды һәм Диплом белән бүләкләнде. 2014 нче уку елында 10 нчы сыйныф укучысы Абдуллина Камилә Г.Тукай исемендәге IV Бөтенроссия шигырь сөйләүчеләр конкурсында уңышлы чыгыш ясаганы өчен Дипломга лаек булды.

Укытучының, сыйныф җитәкчесе буларак та, нәтиҗәле эш алымнары бар. Ул – 5 нче сыйныф укучыларының сыйныф җитәкчесе, гадел һәм әхлаклы укытучы. Укучыларын да үз үрнәгендә тырыш, конкурентлыкка сәләтле, замана балалары итеп тәрбияли. Һәр укучысы һәм ата-аналары белән уртак тел табып, тәрбия өлкәсенә аларны да җәлеп итеп эшли. Тәрбия өлкәсендәге эшчәнлеге белән башка сыйныф җитәкчеләренә дә үрнәк булып тора. Үзенең эш тәҗрибәсе белән уртаклашу максатыннан, төрле темаларга кызыклы тәрбия сәгатьләре, бай эчтәлекле кичәләр үткәрә. Сыйныф җитәкчеләре өчен үткәргән “Игелекләр кылып яшик” дигән тәрбия сәгате моңа ачык мисал булып тора.

Светлана Илдус кызы үзе дә бәйгеләрдә теләп катнаша. Район күләмендә уздырылган “Минем өчен Сибгат Хәким иҗаты ул” иҗади эшләр бәйгесендә III урын яулады һәм грамота белән бүләкләнде. 2013 нче уку елында Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының Бөтенроссия “Туган тел” мастер-класс бәйгесенең район турында 2 нче урын яулады һәм Диплом белән бүләкләнде.

Укытучының югары эшчәнлеген укучыларының Бердәм республика имтиханы нәтиҗәләренә карап та бәяләргә мөмкин. 2014-2015 нче уку елында 11 нче сыйныф укучылары Абдуллина Камилә татар теленнән 86 балл, ә Бариева Инзилә 69 балл җыйнадылар һәм республиканыкыннан югарырак күрсәткечләргә ирештеләр. Бүгенге көндә икесе дә татар теле белгечлеге буенча укуларын дәвам итәләр.

Укытучыларның методик берләшмәсе – ул мәктәп эшчәнлегенең бер тармагы. Һәрбер методик берләшмә – укыту процессын методик яктан тулыландырып торучы звено. Мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучыларының методик берләшмәсе турында бары тик уңай фикерләр генә әйтергә була. Методик берләшмә җитәкчесе – Светлана Илдус кызы үз эшен җиренә җиткереп башкара. Мәктәптә ел саен татар теле һәм әдәбияты атналыгы әзерлекле, укучыларны мавыктыра торган итеп оештырыла. Бер генә язучының, шагыйрьнең дә юбилейлары, туган көннәре читтә калмый, аерым план нигезендә үткәрелә.

Сабиржанова Светлана Илдус кызы җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. Мәктәптә профсоюз оешмасы рәисе вазифасын башкара. Үзенә йөкләтелгән эшне намус белән үти.

Укытучының хезмәте район һәм республика тарафыннан югары бәяләнде. 2012 нче елда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгының Мактау грамотасына лаек булды. 2015 нче елда район мәгариф бүлегенең Рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

Мәгариф бүлеге җитәкчесе: Г.М.Закирова